Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы карары

24.09.2018ел. № 89

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум уздыруны инициатива итәргә:

"2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:

* Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

* Җирлекне төзекләндерүне оештыру;

* Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру;

* Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру;

* Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын оештыру.

ӘЙЕ ЮК»

2. Бу карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерү:

- Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Г Гарифуллин